# КАРАР

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бидәңге авыл җирлегенең Татар Бидәңгесе торак пунктында үткән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**04 август, 2020 ел** **№ 51-1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 56, 25.1 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, “Сез, 2020 елга җыелган 56244 (илле алты мең ике йөз кырык дүрт) сум күләмендәге гражданнарның үзара салым акчаларын “Татар Бидәңгесе авылындагы һәлак булган сугышчылар истәлегенә куелган обелискны ремонтлау”дан “Татар Бидәңгесе авылындагы һәлак булган сугышчылар истәлегенә куелган обелиск территориясен төзекләндерү”гә күчерергә ризамы?” сораулары буенча 2020 елның 4 августында булган гражданнар җыены нәтиҗәләрен кертеп, гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә, сайлау хокукына ия булган 217 җыенда катнашучы кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыены катнашучылары саны – 119 кеше.

Гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары, тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, киләсе рәвештә исәпләнде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенының 119 катнашучысы тавыш бирде;

“Каршы” позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бидәңге авыл җирлегенең Татар Бидәңгесе торак пунктында узган гражданнар җыенын булып узган дип, ә җыен нәтиҗәләрен чын дип тану.

2. “Сез, 2020 елга җыелган 56244 (илле алты мең ике йөз кырык дүрт) сум күләмендәге гражданнарның үзара салым акчаларын “Татар Бидәңгесе авылындагы һәлак булган сугышчылар истәлегенә куелган обелискны ремонтлау”дан “Татар Бидәңгесе авылындагы һәлак булган сугышчылар истәлегенә куелган обелиск территориясен төзекләндерү”гә күчерергә ризамы?” сораулары буенча кабул ителгән карарны тану.

«РИЗА» «КАРШЫ

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен, халыкка җиткерү максатыннан, мәгълүмати стенларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) беркетергә.

4. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына юнәлтергә.

**Гражданнар җыенында**
**рәислек итүче** **Г.З. Галеева**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Бидәңге авыл җирлеге**
**Башлыгы** **Г.З. Галеева**